СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.01.2026 г. Агрыз № 6-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы,Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2013 елның 15 декабрендәге 28-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәсе, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 15.12.2025 елның 4-2 номерлы карары нигезендә, 21.01.2026 елның Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе карарларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 22.01.2026 елдан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына Салихов Илгиз Хәйдәр улын билгеләргә.

2. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясындагы 7 өлешендә билгеләнгән форма буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт төзергә.

3 Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалының Әгерҗе районы «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») газетасында, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми

порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов